Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Чершелы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Чершелы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) урнаштыру, сатып алу)»;

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт валчыклар сатып алу, махсус техника хезмәтләре, Чершелы торак пунктының Луговая урамында)»

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Чершелы авылында гражданнар җыены карарына:

«-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) урнаштыру, сатып алу)»;

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш һәм асфальт валчыклар сатып алу, махсус техника хезмәтләре, Чершелы торак пунктының Луговая урамында)»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кнәз авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Кнәз авыл җирлеге Башлыгы Ф.Ф.Хафизова